**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**КҮЛЛЕ—КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422742, Атнинский район с. Кулле-Кими, ул. Кирова, 1А тел: 8(843-69) 3 - 53 - 40

“12” май 2020 ел №13

**Карар**

**2017 елның 28 февраль «Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 5 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 1 маендагы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 71-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Әтнә районы прокуратурасының 2020 елның 29 апрелендагы протесты нигезендә Карар бирәм:

1.«Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 2017 елның 28 февралендәге 5 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1. 5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:**
«5. Иҗтимагый контроль максатларында фикер алышуны үткәрү вакыты Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә һәм әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганнан соң 5 эш көненнән дә ким булмаска тиеш.»

**2. 6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:**

«6.Заказчылар, әлеге документның 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, электрон яки язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен карый.»

**3. 7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.Заказчылар әлеге документның 5 пунктында күрсәтелгән срок чыкканнан соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында җәмәгать контроле максатларында фикер алышу беркетмәсен урнаштыралар, ул иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның кергән тәкъдимнәрен исәпкә алу турындагы мәгълүматны һәм (яисә) заказчының кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу мөмкинлеге булмау турындагы нигезләнгән позициясен үз эченә алырга тиеш.»